ГЛАВА СРЕДНЕКАМЫШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

УРТА КАМЫШЛА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАШЛЫГЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

Урта Камышлы ав.

КАРАР

«5» ноябрь 2020 ел № 5

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Чияле Алан авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Урта Камышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Чияле Алан торак пунктында Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Чияле Алан авылы, Мәктәп ур., 5 адресы буенча урнашкан Чияле Алан авыл клубында Комсомольская урамы 1-61нче йортларда яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын 2020 елның 20 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Чияле Алан торак пунктында Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Чияле Алан авылы, Мәктәп ур., 5 адресы буенча урнашкан Чияле Алан авыл клубында Ленин урамы 1-53нче йортларда яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын 2020 елның 20 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка билгеләргә

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Чияле Алан торак пунктында Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Чияле Алан авылы, Мәктәп ур., 5 адресы буенча урнашкан Чияле Алан авыл клубында Мәктәп урамы урамы 1-20нче, Клубная урамы1-5нче, Пушкин урамы 1нче йортта, Есенин урамы 1-17нче йортларда яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын 2020 елның 20 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Чияле Алан торак пунктында Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Чияле Алан авылы, Мәктәп ур., 5 адресы буенча урнашкан Чияле Алан авыл клубында Гагарин урамы 1-76нче, Мичурин урамы 1-16нчы йортларда яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының дүртенче этабын 2020 елның 20 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка билгеләргә.

5. Гражданнар җыенын уздыру өчен Чияле Алан авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибе территориаль билге буенча.

6. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге Чияле Алан авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 1000 (мең сум) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

1. Су белән тәэмин итү чыганакларына карата норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару.
2. Торак пункт чикләрендә юлларны ремонтлау
3. 12х12 зурлыгында янгынга каршы көрәш өчен пирс төзү.
4. Тавыш көчәйткеч сатып алу һәм урнаштыру»

«РИЗА» «КАРШЫ»

8. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Чияле Алан авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы А.В. Яманов